**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«10» ноябрь 2021 ел № 20

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башлыгының «Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 9 ноябрендәге 14 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башлыгының «Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 9 ноябрендәге 14 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» (https://tukay.tatarstan.ru/) бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова